КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 май г.Казань № 378

Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру максатларында автотранспорт сатып алу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларны файдалану кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары белән расланган «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасына теркәлгән $8^2$ нче кушымта белән күздә тотылган Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру максатларында автотранспорт сатып алу өчен 2019 елда федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру максатларында автотранспорт сатып алу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларны файдалану кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 8 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 май, 378 нче
карары белән расланган

Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны
Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру
максатларында автотранспорт сатып алу өчен федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган
башка бюджетара трансфертларны файдалану
кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру максатларында автотранспорт сатып алу өчен 2019 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) тоту механизмын (алга таба – Кагыйдәләр) билгели.

2. Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру максатларында автотранспорт сатып алу өчен чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны гамәлгә ашыру максатларында автотранспорт сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бу Кагыйдәләрнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган шәхси счетка керә.

5. Башка бюджетара трансфертлар акчасын тоту Казначылыкта ачылган шәхси исәп аша Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, финанслануның иң чик күләмнәре Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң, биш эш көне эчендә финанслануның иң чик күләмнәрен Министрлыкка тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә ирештерә.

7. Министрлык Татарстан Республикасының дәүләт бюджет яки автоном учреждениеләре булган Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүче комплекслы үзәкләр (алга таба – Комплекслы үзәкләр) белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасының дәүләт

бюджет яки автоном учреждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү төзи һәм Комплекслы үзәкләргә субсидия бирә.

8. Комплекслы үзәкләр квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 13 еннән дә соңга калмыйча, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы хисапны һәм, агымдагы елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча, башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү турындагы хисапны Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча Министрлыкка кертә.

9. Комплекслы үзәкләрнең Казначылыкта ачылган шәхси счетларыннан акча күчерү «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән дәүләт контрактлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Министрлык Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына түбәндәгеләрне кертә:

агымдагы елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча, башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү турындагы хисапны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы хисапны.

11. Бу Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән хисаплар Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча кертелә.

12. Агымдагы финанс елында башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Әгәр дә башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше федераль бюджетка күчерелмәсә, әлеге акча федераль бюджет керемен Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

13. Министрлык законнар нигезендә кертелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау өчен җавап бирә

14. Бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---